ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 101 от «01» 04 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
2021 елның 23 августында кабул ителгән
274 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Мамадыш районы прокурорының 2022 елның 18 мартындагы N02-08-02-2022 протесты, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Башкарма комитет җитәкчесенең 2012 елның 20 июнендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 1090 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 23 августындагы 274 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең Административ регламентларын раслау турында» карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Караның беренче абзацындагы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 880 номерлы карарына таянып,» сүзләрен гамәлдән чыкан дип танырга.

1.2. «Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрлары планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 3 нче кушымтаның 2.5.1. пунктындагы «Индивидуаль торак төзелеше объектын төзү яисә реконструкцияләү» сүзләрен «күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ

0000011356

номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектын төзү, реконструкцияләү» сүзләренә алмаштырырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлегенең җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә секторына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль районының www.mamadysh.tatarstan.ru. рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М. Никифоровка йөкләргә.

Җитәкче И.М.Дәрҗеманов